Кукмара шәһәре Советы
Кукмара муниципаль районы
Татарстан Республикасы

# КАРАР

7 август 2019 ел №17

Кукмара поселок Советының 2012 ел
12 июль 14 номерлы карары белән
расланган Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы «Кукмара
шәһәре» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелешләр
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Кукмара районы прокуроры тарафыннан ачыкланган коррупцион факторны бетерү максатында норматив хокукыйа ктны үзгәртү турында 2019 ел 14 июнь 02-01-22-2018 номерлы таләбен карап, Кукмара шәһәре Советы карар итте:

Кукмара поселок Советының 2012 ел 12 июль 14 номерлы карары (Кукмара поселок Советының 2016 елның 30 сентябрендәге 26, 2019 елның 18 февралендәге 3 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән кулану һәм төзелешләр кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяның 11 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләре белән территориаль зоналарны яки аларның өлешләрен өстәмә юнәлешләр буенча куллануга карата аерым шәһәр төзелеше таләпләре билгеләнә:».

Кукмара шәһәре мэры С. Д. Димитриев